- 120 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (Д-2) төзелеше зонасыннан п/э Ø 63 мм суүткәргеч участогын чыгару ;

-ЖК-1 торак комплексы төзелеше зонасыннан Ø 150 мм суүткәргеч участогын чыгару;

-Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм Ш-1 гомуми белем бирү оешмасы төзелеше зонасыннан гамәлдәге Ø 150 мм булган суүткәргечне сүтү;

- планлаштырыла торган мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларын төзү зонасыннан суүткәргечләрне сүтү»;

3.22. 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.2. Су чыгару.

Су чыгару челтәренә гомуми йөкләнеш 70,16 л/с тәшкил итә (252,58 куб.м/сәг).

ЖК-1 торак комплексы, күпфункцияле үзәк (III), Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, Ш-1 гомуми белем бирү оешмасы өчен Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан бирелгән техник мөмкинлекләр турында 2024 елның 3 октябрендәге исх. 10428/16-29 номерлы хат нигезендә хуҗалык-көнкүреш канализациясенә тоташу ноктасы билгеләнде. Хуҗалык-көнкүреш агынтыларын Варганов урамы буенча Ø 600 мм диаметрлы канализация коллекторына чыгару Тула урамы буенча, Техника урамыннан алып насос станциясе районында 54,25/48,60 тамгалы канализация коесына кадәр Ø 2000 мм коллекторның үткәрү сәләтен торгызу шарты белән башкарыла.

ЖК-2, ЖК-3, ЖК-5 торак комплексларына, Д-2 мәктәпкәчә оешмасына су чыгару Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе биргән 2024 елның 28 маендагы 16558/06/16-29 номерлы техник мөмкинлеге нигезендә Тула урамындагы 2000 мм диаметрлы канализация коллекторына гамәлгә ашырыла.

Техника урамында күпфункцияле үзәкнең (I), амбулатор-поликлиника учреждениесенең (II) һәм ЖК-4 торак комплексының хуҗалык-көнкүреш агынты сулары Магистраль урамындагы чистарту корылмаларына Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе биргән 2021 елның 1 ноябрендәге 07-15/25933 номерлы техник мөмкинлеге нигезендә чыгарыла. Хуҗалык-көнкүреш канализациясенең чыгару трассасы өчен проектны эшләү һәм билгеләнгән тәртиптә килештерү таләп ителәчәк.

Хуҗалык-көнкүреш агынтыларын проектлана торган районнан чыгару өчен планлаштыру проектында түбәндәгеләр каралган:

- Тула урамындагы Ø 2000 мм диаметрлы коллектор участогын Техника урамындагы 17В номерлы йорт янындагы 54,35/48,90 тамгалы канализация коесыннан Тула урамындагы 58 номерлы йорт янындагы 54,74/50,94 тамгалы канализация коесына кадәр күчереп салу;
- Тула урамында Ø 2000 мм диаметрлы коллектор участогын, Техника урамыннан алып насос станциясе районында 54,25/48,60 тамгалы канализация коесына кадәр өлештә күчереп салу (үткәрү сәләтен торгызу);
- хуҗалык-көнкүреш п/э Ø 315 мм, Ø 400 мм, Ø 500 мм канализациясенең коммуналь коллекторының квартал эчендәге челтәрләрен төзү;
- КНС-К насос станциясеннән алып коедагы басымны сүндерү җайланмасына кадәр хуҗалык-көнкүреш 2 Ø 110 мм канализациясенең квартал эчендәге басым коллекторын төзү, озынлыгы 403 п. м.;
- Варганов урамындагы Ø 600 мм диаметрлы коллекторга ЖК-1 торак комплексын, Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасын, Ш-1 гомуми белем бирү оешмасын, күпфункцияле үзәкне (III) тоташтыру максатыннан, диаметрын 500 мм га кадәр арттырып, Варганов урамы буенча Ø160 мм диаметрлы коллекторны күчереп салу, шул ук вакытта булган кулланучыларны күчереп салына торган коллекторга тоташтыру саклана;
- Варганов урамындагы Ø 500 мм диаметрлы күчереп салына торган коллекторга кадәр хуҗалык-көнкүреш канализациясенең Ø п/э Ø 315 мм, Ø400 мм, Ø 500 мм диаметрлы коммуналь коллекторының квартал эчендәге челтәрләрен төзү, аннары Варганов урамындагы Ø 600 мм диаметрлы коллекторга тоташтыру;
- Авангард һәм Варганов урамнары киселешеннән алып Глазунов урамына кадәр Ø 600 мм диаметрлы коллекторның үткәрү сәләтен торгызу;
- ЖК-1 торак комплексы төзелеше зонасыннан гамәлдәге Ø 300 мм диаметрлы коллекторны сүтү;
- Аркылы-Авангард урамындагы 25а йортын хуҗалык-көнкүреш канализациясенең проектлана торган системасына яңадан тоташтыру;

- гамәлдәге коллекторны ЖК-1 торак комплексы төзелеше зонасыннан чыгару;

- гамәлдәге ж/б Ø 500 мм коллекторны чыгару;

- Генераль планда каралган хуҗалык-көнкүреш 2 Ø400 мм канализациясенең транзит коллекторын төзү;

- планлаштырыла торган мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларын төзү зонасыннан сүтелә торган биналарның хуҗалык-көнкүреш канализациясе коллекторларын сүтү»;

3.23. 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.3. Яңгыр канализациясе.

Яңгыр канализациясе челтәренә гомуми йөкләнеш 1532 л/с тәшкил итә.

ЖК-1 торак комплексы, күпфункцияле үзәк (III), Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, Ш-1 гомуми белем бирү оешмасы территориясеннән җир өстендәге агынты суны Авангард урамындагы Ø 700 мм коллекторга чыгару Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты тарафыннан бирелгән 2024 елның 9 апрелендәге 02-41/978 номерлы яңгыр һәм кар суларын агызуга техник шартларга туры китереп башкарыла.

Капиталь төзелешнең планлаштырыла торган башка объектлары өчен агынты суларны чыгару Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты тарафыннан бирелгән яңгыр һәм кар суларын агызу өчен 2021 елның 25 октябрендәге 02-41/2738 номерлы техник мөмкинлеге нигезендә гамәлгә ашырыла. Территориядән яңгыр һәм кар сулары проектлана торган комплексларның җир кишәрлекләрендә урнаштырыла торган локаль чистарту корылмаларына җибәрелә, аннан соң чистартылган агынтылар Техника урамындагы Ø 300 мм яңгыр канализациясе коллекторына чыгарыла.

Проектлана торган район территориясеннән агынты суларны чыгару өчен планлаштыру проектында түбәндәгеләр каралган:

- ЛОС-1, ЛОС-2, ЛОС-3 локаль чистарту корылмалары төзү;

- ЛОС-1, ЛОС-2, ЛОС-3 локаль чистарту корылмаларына кадәр квартал эчендәге үзагышлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү;

-КНС-Кл насос станциясен төзү;

- КНС-Кл насос станциясеннән алып коедагы 400 п. м озынлыктагы басымны сүндерү җайланмасына кадәр 2 Ø 110 мм яңгыр канализациясенең квартал эчендәге басым коллекторын төзү;

- Техника урамы буйлап 700 мм озынлыктагы кызыл линияләрдә коллекторга тоташтыру ноктасына кадәр яңгыр канализациясенең үзагышлы челтәрләрен төзү;

- торбаның диаметрын 300 мм дан 1000 мм га кадәр арттырып, Техник урамында яңгыр канализациясен коллекторын күчереп салу;

- Владимир Кулагин урамындагы 9 номерлы йорттан алып Авангард урамына кадәр Ø 500 мм үзагышлы яңгыр канализациясе участогы төзү;

- Владимир Кулагин урамындагы Ø 500 мм диаметрлы булган яңгыр канализациясе участогын реконструкцияләү;

– квартал эчендә , шул исәптән яңгыр суларын Авангард урамындагы 147а һәм 147б номерлы йортларның ишегалды территориясеннән, Авангард урамындагы 159 йорт адресы буенча 3 номерлы балалар бакчасыннан – проект чикләреннән читкә чыгару өчен басымлы һәм үзагышлы яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү;

- планлаштырыла торган мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларын төзү зонасыннан сүтелә торган биналарның яңгыр канализациясе коллекторларын сүтү»;

3.24. 5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.4. Җылылык белән тәэмин итү.

Җылылык белән тәэмин итү челтәргә гомуми йөкләнеш 8,68 Гкал/сәг тәшкил итә.

Планлаштыру проекты территориясендә ЖК-3, ЖК-4 торак комплексларын, амбулатор-поликлиника учреждениесен (II), Техника урамы буенча күпфункцияле үзәкне (I) җылылык белән тәэмин итү «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте 2021 елның 8 ноябрендәге бирелгән тоташтыруның техник мөмкинлеге һәм 2021 елның 16 декабрендәге бирелгән чыгаруның техник мөмкинлеге нигезендә 2 Ø 530 мм диаметрлы магистраль җылылык үткәргеченнән Техника урамы буенча ОП-223 кә каралган.

ЖК-1 торак комплексын, Д-1 мәктәпкәчә оешмасын, Ш-1 гомуми белем бирү учреждениесен җылылык белән тәэмин итү өчен блоклы-модульле К-2 газ котельные каралган.

ЖК-2, ЖК-5 торак комплексларын, Д-2 мәктәпкәчә оешмасын җылылык белән тәэмин итү кадастр номеры 16:50:080213:69 булган җир кишәрлегендә урнаштырыла торган блок-модульле К-3 газ котельныеннан каралган.

Проектлана торган район территориясен җылылык белән тәэмин итү өчен планлаштыру проектында түбәндәгеләр каралган:

- ТК1-10нан ОП-150гә кадәр участокта диаметрын арттырып, гамәлдәге үткәргеч торбаны реконструкцияләү;

- ТК1-31дән ТК1-37гә кадәр участокта диаметрны арттырып, гамәлдәге үткәргеч торбаны реконструкцияләү;

- 2 Ø 530 мм үткәргеч торба участогын җир астына үзгәртеп корып, ЖК-3 торак комплексы төзелеше зонасыннан чыгару;

- ЖК-4 һәм амбулатория-поликлиника учреждениесе (II) ягына тармакланып, ОП-223 дән квартал эчендәге яңа җылылык челтәрләре 2 Ø 225 мм төзү;

- Д-2 мәктәпкәчә оешмасын (16:50:000000:6675 кадастр номерлы җир кишәрлеге) урнаштыруны тәэмин итү өчен 2 Ø 325 мм җылылык үткәргечне традицион изоляциядә чыгару 16:50:000000:6675);

- Авангард урамы, 90 адресы буенча урнашкан бинаны җылылык белән тәэмин итү өчен ППУ-изоляциядә 2 Ø 159 мм җылылык үткәргечне чыгару;

- ТК1-49 дренаж җайланмасын чыгару;

- Тульская урамы, 56 (корп.1) адресы буенча булган бинаны күчерелә торган җылылык үткәргечкә яңадан тоташтырып чыгару;

- планлаштырыла торган мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларын төзү зонасыннан сүтелә торган биналарның җылылык үткәргечләрен сүтү»;

3.25. 5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.5. Газ белән тәэмин итү.

Газ белән тәэмин итү челтәренә гомуми йөкләнеш 6179,2 куб.м/сәг тәшкил итә.

Җитештерү процессларын үзгәртеп кору максатларында «Вакуummаш» акционерлык җәмгыяте предприятиесендә К-1 котельныйсын урнаштыру каралган. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелгән 2022 елның 6 июлендә 481-22-ТП номерлы техник шартларга туры китереп, Авангард урамы буйлап уртача басымлы газүткәргечкә тоташтыру ноктасыннан алып проектлаштырыла торган К-1 котельныйга кадәр Аркылы-Авангард урамы буйлап 395 п.м озынлыктагы урта басымлы газүткәргеч төзү планлаштырыла.

ЖК-1 торак комплексын, Д-1 мәктәпкәчә оешмасын һәм Ш-1 гомуми белем бирү учреждениесен җылылык белән тәэмин итү өчен 26,3 МВт куәтле К-2 блоклы-модульле котельныйны урнаштыру планлаштырыла. Тоташтыру «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан бирелгән техник шартларга (2400-000372-24-ТП номерлы шартнамәгә 1 номерлы кушымта) туры китереп, Авангард урамы буйлап уртача басымлы (басым 0,18 МПа) Ø 426 мм газүткәргечкә тоташтыру ноктасыннан проектлана торган котельныйга кадәр гамәлгә ашырыла.

ЖК-2, ЖК-5 торак комплексларын, Д-2 мәктәпкәчә оешмасын җылылык белән тәэмин итү өчен 6,0 МВт куәтле блоклы-модульле К-3 котельныен урнаштыру планлаштырыла. Тоташу ноктасы «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан 2024 елның 26 августындагы Исх-06/3-9752 номерлы бирелгән техник мөмкинлекләр турында хат нигезендә, уртача басымлы Ø 530 мм газүткәргечтән Җиңү проспекты һәм Оренбург

тракты кисешкән урында билгеләнде. Газ бирү «Богородское» газ бүлеп тарату станциясеннән бирү күздә тотыла. Газүткәргечнең үткәргеч трассасы өчен проектны эшләү һәм билгеләнгән тәртиптә килештерү таләп ителәчәк.

Территориядә планлаштырылган объектларны газ белән тәэмин итү өчен түбәндәгеләр каралган:

- Аркылы-Авангард урамы буйлап 395 п. м озынлыктагы уртача басымлы газүткәргеч төзү, Авангард урамы буйлап Ø 426 мм диаметрлы урта басымлы газүткәргечкә тоташтыру ноктасыннан алып проектлана торган К-1 котельныйга кадәр, К-1 БМК төзү;

- Авангард урамы буйлап уртача басымлы газүткәргечкә тоташу ноктасыннан алып гомуми озынлыгы 175 м булган К-2 блоклы-модульле котельныйга кадәр Ø 426 мм диаметрлы урта басымлы газүткәргеч төзү;

- 26,3 МВт куәтле К-2 газ блоклы-модульле котельныйны төзү;

- ЖК-1 торак комплексы, Д-1 мәктәпкәчә оешмасы һәм Ш-1 гомуми белем бирү оешмасы объектларында К-2 котельныеннан шәхси җылылык пунктына кадәр җылылык челтәрләре төзү;

- Җиңү проспекты һәм Оренбург тракты кисешкән урында тоташу ноктасыннан алып диаметры Ø 530 мм булган уртача басымлы газүткәргечтән алып гомуми озынлыгы 2,98 км булган К-3 блоклы-модульле котельныйга кадәр урта басымлы газүткәргеч төзү;

- кадастр номеры 16:50:080213:69 булган җир кишәрлегендә 6,0 МВт куәтле К-3 блоклы-модульле котельныйны төзү;

- ЖК-2 торак комплексы һәм Д-2 мәктәпкәчә оешмасы объектларында К-3 котельныеннан шәхси җылылык пунктына кадәр җылылык челтәрләре төзү;

- җир астында гамәлгә куеп үзгәртеп корып, ЖК-1 торак комплексы объектларын төзү зонасыннан уртача басымлы газүткәргеч чыгару»;

3.26. 5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.6. Электр белән тәэмин итү.

Электр белән тәэмин итү челтәренә гомуми йөкләнеш 10,092 МВт тәшкил итә.

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан бирелгән 2022 елның 17 гыйнварындагы 8 номерлы техник таләпләр нигезендә электр белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләрен проектлаштыруга һәм электр энергиясен коммерцияле исәпкә алуны оештыруга туклану чыганыгы булып «Искож» подстанциясе, яңа бүлү трансформатор пункты һәм блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе тора (РТП һәм БКТП). «Челтәр компаниясе » акционерлык җәмгыяте объектына тоташу ноктасы проектлау чикләреннән читтә урнашкан. Трасса аерым эш проекты белән эшләнәчәк.

ЖК-1 торак комплексын, күпфункцияле үзәкне (III), Д-1 мәктәпкәчә белем бирү оешмасын, Ш-1 гомуми белем бирү оешмасын электр белән тәэмин итү «Энерго «СК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан 2023 елның 3 ноябрендә бирелгән 2023/СК/К/УС/023 номерлы хаты нигезендә каралган. Төп һәм резерв туклану чыганагы булып «Искож» подстанциясе, «Теплоконтроль» акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы үзәк бүлү подстанциясе-6 кВ (ЦРП-6 кВ) тора.

Территорияне электр белән тәэмин итү өчен планлаштыру проектында түбәндәгеләр каралган:

- «Искож» подстанциясендә тоташу ноктасыннан РТП (6/0,4 кВ) бүлү подстанциясенә кадәр 720 п.м гомуми озынлыктагы 6 кВ югары көчәнешле кабель линияләрен төзү;

- РТП (6/0,4 кВ) бүлү подстанциясеннән БКТП №4, БКТП №5, БКТП №6, кертелгән КТП-7 комплектлы трансформатор подстанциясенә кадәр 6 кВ кабель линияләрен төзү;

- «Теплоконтроль» акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы үзәк бүлү подстанциясеннән-6 кВ (ЦРП-6кВ) БКТП №1, БКТП №2, БКТП №3 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенә кадәр 471 п.м гомуми озынлыктагы 6 кВ кабель линияләрен төзү;

- проектлана торган БКТП-4 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясеннән гамәлдәге ТП-455 трансформатор подстанциясенә кадәр 6 кВ кабель линиясе төзү;

- проектлана торган БКТП-5 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясеннән гамәлдәге ТП-1413 трансформатор подстанциясенә кадәр 6 кВ кабель линиясе төзү (Техника урамы, 52, корп.1 бинасына кертелгән);

- Блочная комплектлы трансформатор подстанцияләре БКТП №1, БКТП №2, БКТП №3, БКТП №4, БКТП №5, БКТП №6, урнаштырылган КТП төзелеше;

- БКТП-6/0,4 кВ блоклы комплектлы трансформатор подстанциясеннән объектларның ВРУ кертү-бүлү җайланмасына кадәр 0,4 кВ түбән көчәнешле кабель линияләрен төзү;

- тышкы яктыртуның түбән көчәнешле челтәрен салу;

- ЖК-1, ЖК-2, ЖК-5 торак комплекслар һәм гомуми белем бирү учреждениесе төзелеше территориясеннән югары көчәнештәге кабель линиясенең ике җебен сүтү;

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе төзелеше территориясеннән Д-2 югары көчәнештәге кабель линиясенең ике җебен чыгару;

- ЖК-1 торак комплексы төзелеше территориясеннән кабель линиясен чыгару;

- 110 кВ ВЛ ТЭЦ-1 – «Искож» ПС – «Южная» ПС җир астында гамәлгә куеп үзгәртеп кору (ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар көче белән башкарыла);

- сүтелә торган биналарны тәэмин итүче кабель һәм һава электр тапшыру линияләрен, планлаштырылган мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмалары төзелеше зонасыннан сүтү;

3.27. 5.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«ЖК-1 торак комплексын, Д-1 мәктәпкәчә оешмасын һәм Ш-1 гомуми белем бирү учреждениесен электр элемтәсе белән тәэмин итү "Уфанет" акционерлык җәмгыятенең Казан филиалы тарафыннан 2023 елның 25 маенда бирелгән К-133СП-2023 номерлы техник шартлар нигезендә планлаштырыла.»;

3.28. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«7. Территорияне Казан шәһәр округының расланган генераль планы нигезендә үстерү.

Казан шәһәре Думасының 2024 елның 28 августындагы 2-32 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы “Казан шәһәр округының генераль планын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә территория чикләренә түбәндәге зоналар кертелгән:

- күпфункцияле үсеш зонасы, торак фондының билгеләнгән лимитыннан башка 53,518 га мәйданлы планлаштыру проектын (ФЗ 123, ID 1077) эшләү шарты белән территорияне үзләштерү;

- 7,027 га мәйданлы җитештерү, коммуналь-склад объектларын һәм торак төзелеше участокларын (ФЗ 320, ID 1093) торак фонды мәйданы буенча билгеләнгән чикләүләрдән башка катнаш урнаштыру зонасы;

- мәйданы 8,238 га булган III-V класслы куркыныч һәм коммуналь-склад билгеләнешендәге (ФЗ 3002, ID 2240) җитештерү объектларын урнаштыру зонасы»;

3.29. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

8. Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү характеристикасы.

8.1. Гомуми нигезләмәләр

Урамнарның кызыл линияләре чикләрендәге территорияне яшелләндерүнең гомуми мәйданын 122 793 кв. м га җиткерү планлаштырыла, шул исәптән:

- 13 500 кв.м – гомуми файдаланудагы яшелләндерү;

- 13 028 кв.м – урамнарның кызыл линияләрендә яшелләндерү;

- 96 265 кв.м – торак, иҗтимагый-эшлекле һәм коммуналь-склад төзелешендә яшелләндерү (җир кишәрлекләрендә яшелләндерү).

Территориядә торак фондының гомуми саны, гамәлдәге һәм планлаштырыла торган объектларны исәпкә алып, 227 155,5 кв.м тәшкил итә, шуларның 221 200 кв. м – яңа торак фонды, 5955,5 кв. м – гамәлдәге торак фонды.

Исәпләнгән халык саны 227 155,5/30 = 7572 кеше тәшкил итә. Халык саны үсеше 221200/30 = 7373 кеше тәшкил итәчәк. Микрорайонның яшелләндерелгән территориясе бер кешегә 122793/7572 = 16,22 кв. м тәшкил итә. Территорияне төзегәндә яшелләндерүнең минималь мәйданы бер кешегә 0,6 кв. м тәшкил итә.

Проект буенча җәяүлеләр өчен яңа тротуарлар һәм велосипед юлларын төзү һәм гамәлдәгеләрен реконструкцияләү планлаштырыла.

8.2. Территорияне планлаштыру проектында каралган табигать-рекреация комплексы объектлары исемлеге.

Планлаштыру проектында 4 нче таблицада күрсәтелгән табигать-рекреация комплексы объектлары карала.

4 нче таблица

| **Территорияне планлаштыру сызымында капиталь төзелеш объектлары зонасы номеры** | **Табигать-рекреация комплексы объектларының таләп ителә торган минималь мәйданы, га** | **Табигать-рекреация комплексы объектларының мәйданы, га** | **Функциональ зона** |
|---|---|---|---|
| 26 | 0,05 | 0,17 | ID 1077, ФЗ 123 |
| 27 | — | 0,41 | ID 1077, ФЗ 123 |
| 28 | — | 0,04 | ID 1077, ФЗ 123 |
| 29 | — | 0,07 | ID 1077, ФЗ 123 |
| 30 | — | 0,04 | ID 1077, ФЗ 123 |
| 31 | 0,2 | 0,18 | ID 1093, ФЗ 320 |
| 32 | 0,05 | 0,18 | ID 1077, ФЗ 123 |
| 34 | 0,2 | 0,26 | ID 1077, ФЗ 123 |
| **БАРЛЫГЫ** | — | **1,35** | —» |

4. Территорияне план буенча үстерү чираты турындагы нигезләмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

## «IV. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә

5 нче таблица

## Территорияне план буенча үстерү чиратлылыгы турында гамәлгә ашыруның этаплары һәм максималь сроклары булган нигезләмә

| **1 нче этап** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Капиталь төзелеш объектлары төрләре** | **Объектлар** | **Капиталь төзелеш объектлары урнашту зонасы номеры** | **Максималь сроклар, ел** | | |
| | | | **Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (җир кишәрлеген формалаштыру/архитектура ягыннан проектлаштыру /экспертиза)** | **Сүтү** | **Төзү** |
| Торак билгеләнеш ендәге | ЖК-1 торак комплексы (1 нче чират) | 8 | 2025 | 2025 | 2026 |
| | ЖК-2 торак комплексы (1 нче чират) | 4 | 2026 | 2025 | 2027 |
| | ЖК-1 торак комплексы 2 нче чират: | 8 | 2027 | 2025 | 2030 |
| | ЖК-2 торак комплексы 2 нче чират: | 4 | 2027 | 2026 | 2028 |
| | ЖК-3 торак комплексы | 2 | 2027 | 2027 | 2029 |
| | ЖК-5 торак комплексы | 45 | 2029 | - | - |
| Инженерлык инфраструктурасы | Котельный | 35 | 2026 | 2026 | 2027 |
| | Котельный | 40 | 2025 | 2025 | 2026 |
| | Трансформатор подстанциясе, локаль чистарту корылмалары | 36 | 2026 | 2026 | 2027 |
| | Инженерлык инфраструктурасы объектлары | - | 2029 | 2027 | 2030 |
| Социаль инфраструктура | (Д-1) мәктәпкәчә белем бирү оешмасы | 9 | 2026 | 2025 | 2028 |
| | (Д-2) мәктәпкәчә белем бирү оешмасы | 14 | 2030 | - | - |
| | (Ш-1) гомуми | 9 | 2030 | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | белем бирү учреждениесе | | | | |
| | (II) амбулатор-поликлиника учреждениесе | 7 | 2030 | - | - |
| Җитештерү билгеләнеш ендәге | «Вакууммаш» АҖ кою производствосы корпусы (IV) | - | 2026 | - | 2028 |
| Башка объектлар | (III) автотранспортны саклау урыннары урнашкан физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен бинаалары булган күпфункцияле үзәк ЖК-1 торак комплексын тәэмин итү өчен) | 11 | 2026 | 2025 | 2027 |
| Транспорт инфраструктурасы | 1 номерлы урам | - | 2027 | - | - |
| | 2 номерлы юл | - | 2027 | - | - |

## 2 нче этап

| **Капиталь төзелеш объектлары төрләре** | **Объектлар** | **Капиталь төзелеш объектлары урнаштыру зонасы номеры** | **Максималь сроклар** | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (җир кишәрлеген формалаштыру/архитектура ягыннан проектлаштыру /экспертиза)** | **Сүтү** | **Төзү** |
| Торак билгеләне шендәге | ЖК-5 торак комплексы | 45 | - | - | 2031 |
| | ЖК-4 торак комплексы | 17 | 2031 | - | 2032 |
| Социаль инфраструктура | (Д-2) мәктәпкәчә белем бирү оешмасы | 14 | - | 2030 | 2031 |
| | (Ш-1) гомуми белем бирү учреждениесе | 9 | - | 2030 | 2031 |
| | (II) амбулатор-поликлиника учреждениесе | 7 | - | 2030 | 2031 |
| Инженерлык инфраструктурасы | Инженерлык инфраструктурасы объектлары | - | 2031 | - | 2032 |
| Иҗтимагый-эшлекле | (I) Техника урамы буенча | 1 | 2030 | 2031 | 2032 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| билгеләнеш тәге | күпфункцияле үзәк | | | | |
| Транспорт инфраструктурасы | 1 номерлы урам | - | - | 2030 | 2031 |
| | 2 номерлы юл | - | - | 2030 | 2031 |
| Җитештерү билгеләнешендәге | «Вакууммаш» АҖ (V) механик цехы. | - | 2031 | - | 2033 |
| | (VI) Склад корпуслары . | - | 2031 | - | 2033 |

Искәрмә:

1. Социаль объектларны архитектура-төзелеш ягыннан проектлау һәм төзү тиешле социаль программаларга кертелгәндә, территорияне планлаштыруның әлеге проектына үзгәрешләр кертмичә, күрсәтелгән сроклардан иртәрәк гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Төзелешләре 2 нче этапта каралган барлык объектлар өчен архитектура-төзелеш ягыннан проектлау вакытыннан алда 1 нче этапта башкарырга рөхсәт ителә.

3. Этапны гамәлгә ашыру вакытыннан алда төгәлләнгән очракта, аннан соңгы этапның тиешле вакытыннан алда башлануы рөхсәт ителә.

4. «Автотранспортны саклау урыннары урнаштырылган физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен биналары булган күпфункцияле үзәк» объектын файдалануга тапшырганчы, ЖК-1 торак комплексының I чиратын тәэмин итү өчен парковка урыннары урнаштыру кадастр номеры 16:50:080216:856 булган җир кишәрлегендә карала.

5. Архитектура-төзелеш проектлауның, төзелешнең һәм җимерүнең максималь срокларын үзгәртү территорияне планлаштыруның әлеге проектына үзгәрешләр кертүне таләп итми.


6. 5 нче таблицаның 6 баганасында « - » сызыгы белән күрсәтелгән якынча урынлы (инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен бүлеп бирелгән зонадан тыш) инженерлык инфраструктурасы объектларын төзүнең максималь сроклары аларны тәэмин итү өчен каралган капиталь төзелеш объектларын (шул исәптән чиратлар буенча) төзүнең максималь срокларына бәйләнгән.

5. Территорияне план буенча үстерү чиратлыгы турындагы нигезләмәгә әлеге үзгәрешләргә 4 номерлы кушымта нигезендә территорияне план буенча үстерү чиратлыгы схемасын өстәргә.

---

**I. Чертеж Проекта планировки с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды, границы существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границы зон размещения объектов капитального строительства**

**Приложение №1 к изменениям, вносимым в проект планировки территории, ограниченной улицами Техническая, Владимира Кулагина, Авангардная в Приволжском районе г.Казани, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 26.07.2023 №2122**




## УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

**Границы территории, линии регулирования, значения показателей, объекты капитального строительства**

- граница проекта планировки территории
- граница элемента планировочной структуры
- линия регулирования застройки
- границы земельных участков
- красная линия — действующая красная линия улично-дорожной сети
- красная линия — устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- кл ТОП — отменяемая красная линия озеленения общего пользования
- кл ТОП — устанавливаемая красная линия озеленения общего пользования
- кл ТОП — действующая красная линия озеленения общего пользования
- 1 — порядковый номер зоны размещения
- 5 — вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 1.20 — площадь зоны размещения, га
- 4.4 — коды видов разрешенного использования
- н.у. — максимальная площадь жилищного фонда, тыс. кв.м.
- 3 — максимальная этажность, этаж
- ЖК-1 — условный номер жилого комплекса
- Д-1 Ш-1 — условный номер учебно-образовательных объектов
- I-V — условный номер объектов нежилого назначения
- P — места хранения и парковки автотранспорта, планируемые
- P — места хранения и парковки автотранспорта, существующие
- автозаправочная станция, существующая
- трансформаторная подстанция, существующая
- существующая застройка, подлежащая сносу с целью освобождения территории в установленном законом порядке
- существующая сохраняемая застройка

**Границы зон размещения объектов капитального строительства**

- 1 — зона размещения многоквартирной многоэтажной жилой застройки (высотной застройки), планируемые
- 2 — зона размещения среднеэтажной жилой застройки (от пяти до восьми этажей, включая мансардный), планируемые
- 2 — зона размещения среднеэтажной жилой застройки (от пяти до восьми этажей, включая мансардный), существующие
- 5 — зона размещения объектов общественно-делового назначения, планируемые
- 5 — зона размещения объектов общественно-делового назначения, существующие
- 6 — зона размещения образовательных организаций, планируемые
- 6 — зона размещения образовательных организаций, существующие
- 7 — зона размещения объектов здравоохранения, планируемые
- 10 — зона размещения складских и производственных объектов, существующие
- 11 — зона размещения объектов инженерной инфраструктуры, планируемые
- 11 — зона размещения объектов инженерной инфраструктуры, существующие
- 12 — зона размещения объектов транспортной инфраструктуры, существующие
- 12 — зона размещения объектов транспортной инфраструктуры, планируемые
- 20 — зона зеленых насаждений общего пользования, планируемая
- 21 — зона улично-дорожной сети, планируемая
- зона улично-дорожной сети, существующая

**Объекты инженерной инфраструктуры (ориентировочное местоположение)**

- котельная, планируемая
- котельная, существующая
- очистные сооружения дождевой канализации, планируемые
- насосная станция дождевой канализации (НСДК), планируемая
- трансформаторная подстанция, планируемая
- насосная станция хозяйственно-бытовой канализации, планируемая

**Экспликация проектируемых объектов капитального строительства**

ЖК - обозначение жилого комплекса
Д-1, Д-2 - дошкольная образовательная организация
Ш-1 - общеобразовательная организация
I - многофункциональный центр по ул.Техническая
II - Амбулаторно-поликлиническое учреждение
III - многофункциональный центр с помещениями для занятий физкультурой и спортом, с размещением мест для хранения автотранспорта (для обеспечения ЖК-1)
IV - корпус литейного производства АО "Вакууммаш"
V - механический цех АО "Вакууммаш"
VI - складской корпус АО "Вакууммаш"
VII - остановка общественного транспорта (реконструкция)


0 20 40 60 80 метры

М 1:2000

ФОРМАТ А1

**Приложение №2 к изменениям, вносимым в проект планировки территории, ограниченной улицами Техническая, Владимира Кулагина, Авангардная в Приволжском районе г.Казани, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 26.07.2023 №2122**

## II. Чертеж проекта планировки с указанием характерных точек красных линий




**УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ**

- граница проекта планировки территории
- линия регулирования застройки
- границы земельных участков
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия озеленения общего пользования
- устанавливаемая красная линия озеленения общего пользования
- действующая красная линия озеленения общего пользования
- т2 — условный номер характерной точки устанавливаемой красной линии

0 20 40 60 80 метры

ФОРМАТ А1

**Схема с указанием очередности планируемого развития территории**

**Приложение №4 к изменениям, вносимым в проект планировки территории, ограниченной улицами Техническая, Владимира Кулагина, Авангардная в Приволжском районе г.Казани, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 26.07.2023 №2122**

